ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021 ел 8 ноябрь

№ 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегендә Бикмәт авылы гражданнарының 202 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Түбән Бикмәт авылы, Чапаев ур., 42а адресы буенча урнашкан Бикмәт авылындагы фельдшер-акушерлык пункты бинасында 2021 елның 18 ноябренә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Кәүҗияк авылы җирлеге Бикмәт авылында теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Түбән Бикмәт т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру);

2) Түбән Бикмәт т. п. вак таш түшәмнәрен ремонтлау (вак таш ташу) ;

3) некрологларны район «Сарман»газетасында бастырып чыгару. ;

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә, Кәүҗияк авылы территорясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов